**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-02-22, факс (85552) 3-13-44, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
14. 05. 2019

К А Р А Р
ПР-108

"Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының муниципаль милкендәге мөлкәт объектлары турында мәгълүматны бастырып чыгару тәртибен раслау хакында"

Муниципаль милекне нәтиҗәле һәм рациональ файдалану максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Президентының 2018 елның 15 маендагы Пр-817ГС номерлы утырышы йомгаклары буенча йөкләмәләре исемлеген гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мөрәҗәгатен карап, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының муниципаль милегендә булган мөлкәт объектлары турында мәгълүматны бастырып чыгару тәртибен расларга (1 нче кушымта).

2. Актаныш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Актаныш муниципаль районының муниципаль милкендә булган мөлкәт объектлары турында мәгълүматны Актаныш муниципаль районы (aktanysh.tatarstan.ru) сайтында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Башкарма комитеты җитәкчесе И. Ш. Бариев

Шәйхетдинова О. Э.
3-44-92

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитетның
«___» _____05_____ 2019елның
№ПР-108нче
карары белән расланган
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының муниципаль милегендә булган мөлкәт объектлары турында мәгълүматны бастырып чыгару Тәртибе**

1. Әлеге тәртип Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (алга таба Интернет челтәре) Актаныш муниципаль районының муниципаль милегендә булган күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бастырып чыгару процедурасын, аңа аны алу белән кызыксынучы затлар даирәсеннән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында билгели.
2. Актаныш муниципаль районының муниципаль милкендә булган күчемсез милек объектлары турындагы мәгълүматны интернет челтәрендә бастырып чыгару өчен Актаныш муниципаль районы сайты булып тора (http://aktanysh.tatarstan.ru).
3. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының муниципаль милегендә булган күчемсез милек объектлары турындагы мәгълүматны Интернет челтәрендә бастыруга вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы булып тора.
4. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының муниципаль милкендәге күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бастырылырга тиеш.

Россия Федерациясе законнары нигезендә чикләнгән мәгълүмат бастырып чыгарылырга тиеш түгел.

5. Актаныш муниципаль районының муниципаль милкендә булган күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат әлеге тәртип буенча №1,2 кушымта нигезендә объектлар исемлеге рәвешендә басылып чыга.
6. Муниципаль милектә булган күчемсез милек объектлары турындагы мәгълүматны бастырып чыгару, Актаныш муниципаль районы милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасында Актаныш муниципаль районы муниципаль мөлкәт реестрында булган белешмәләр нигезендә, гамәлгә ашырыла.
7. Актаныш муниципаль районының муниципаль милегендә булган күчемсез милек объектлары турында бастырып чыгарылган мәгълүматны актуальләштерү Актаныш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан квартал саен башкарыла.

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының муниципаль милегендә булган мөлкәт объектлары турында мәгълүматны бастырып чыгару тәртибенә
1 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Муниципаль милек реестры

| № п/п | объект исеме | Урнашу урыны | Мәйданы, кв.м. | Максатчан билгеләнеше | Чикләмә | Куллануга чикләү |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Татарстан Республикасы Актаныш
муниципаль районының муниципаль
милегендә булган мөлкәт объектлары
турында мәгълүматны бастырып чыгару
тәртибенә
2 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Муниципаль милек реестры

| № п/п | объект исеме | Урнашу урыны | Мәйданы, кв.м. | Максатчан билгеләнеше | Миле кче | Куллануга чикләү |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |